**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«06» 08 2024 ел Яр Чаллы ш. № 3510

«Истоки» район фольклор коллективлары фестивален үткәрү турында

Милли мәдәниятkә мәхәббәт тәрбияләү, милли фольклор, халык традицияләре һәм йолалары белән танышу максатында, «Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестивален уздырырга.

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның августында Тукай муниципаль районы авыл җирлекләрендә «Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестивален уздырырга.
2. «Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестивале нигезләмәсен расларга (1 кушымта).
3. Фестивальнең оештыру комитеты составын расларга (2 кушымта).
4. Фестивальнең жюри составын расларга (3 кушымта).
5. Чараны үткәрүгә чыгымнар сметасын «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ акчалары хисабына расларга (4 кушымта).
6. Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры А.С. Габдуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның «06» 08 3510 номерлы карарына 1 кушымта

**«Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестивален үткәрү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре арасында «Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестиваленең статусын; структурасына, максатларына, бурычларына таләпләрне; оештыру тәртибен һәм үткәрү регламентын билгели.

1.2. Фестиваль район чарасы статусына ия.

1.3. Фестиваль «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе инициативасы белән яшьләрнең һәм урта һәм өлкән яшьтәге конкурсантларның иҗади сәләтләрен үстерү максатында үткәрелә.

1.4. Фестивальнең координаторы һәм оештыручысы булып «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тора.

1.5. Фестиваль нәтиҗәләре Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында tukay.tatarstan.ru, ВКонтакте социаль челтәрендә https://m.vk.com/kulturnaya_ploshadka_tmr «Культурная площадка ТМР» төркемендә һәм «Якты юл» газетасында басылып чыгачак.

## 2. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Фестивальнең максаты – милли мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү, фольклор белән, халык традицияләре һәм йолалары белән белән танышу. Тукай муниципаль районы халкының иҗади инициативасын активлаштыру, үстерү һәм аңа ярдәм итү, халыкның төрле категорияләрен иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү.

2.2. Фестивальнең бурычлары:

- милли фольклор мәдәниятен үстерү, саклау;
- үз халкың һәм туган ягың тарихы белән кызыксынуны үстерү;
- традицияләрне торгызу, үсеп килүче буынны халык фольклор иҗатына тарту;
- талантлы яшьләрне, коллективларны ачыклау;
- әхлак, эстетика, буыннар дәвамчанлыгын формалаштыру;
- үсеп килүче буында үз халкы, милләте өчен горурлык хисе формалаштыру;
- катнашучыларның сәнгать осталыгын, иҗат коллективлары җитәкчеләренең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү;
- фольклор иҗаты өлкәсендә яңа белемнәр, күнекмәләр алу;

- иң талантлы иҗади башкаручыларның (коллективларның һәм солистларның) шәһәр, төбәк һәм халыкара дәрәҗәдәге чараларда катнашуын тәэмин итү.

## 3. Фестивальне үткәрү сроклары

3.1 Фестиваль өч этапта уздырыла:
3.2. 29.07-02.08.2024 ел – әзерлек этабы: Нигезләмәне формалаштыру, мәгълүмат контентын эшләү, җәмәгатьчелеккә һәм потенциаль катнашучыларга смотр-конкурс уздыру турында мәгълүмат җиткерү.
3.3. 05.08-14.08.2024 ел – Kultura.Tuk@tatar.ru адресы буенча гаризалар кабул итү.
3.4. 20.08-24.08.2024 ел – сайлап алу туры авыл җирлекләрендә алдан төзелгән график буенча үткәрелә, «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнә;
3.5. Финалны үткәрү сроклары фестивальнең сайлап алу туры тәмамланганнан соң игълан ителәчәк. Гала-концерт, җиңүчеләрне бүләкләү;
3.6. Уздыру урыны өстәмә хәбәр ителәчәк.

## 4. Фестиваль җитәкчелеге

4.1. Оештыру комитеты составы Нигезләмә белән билгеләнә (2 кушымта) һәм «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры боерыгы белән раслана.
4.2. Оештыру комитетына рәис җитәкчелек итә.
4.3.Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне башкара:
- фестивальгә гомуми җитәкчелек итә;
- фестивальнең Нигезләмәсен эшли һәм раслый, фестивальне үткәрү вакытын һәм тәртибен, чыгышларны бәяләү критерийларын планлаштыра;
- фестиваль партнерларын һәм иганәчеләр җәлеп итү буенча эш алып бара, кызыксынган яклар (оешмалар) белән хезмәттәшлек итә;
- фестивальнең жюри составын формалаштыра, жюри әгъзаларының эшен тәэмин итә;
- фестиваль чаралары планын эшли;
- фестивальнең гала-концертын уздыруның сценарий планын эшли;
- фестивальнең фирма стилен (логотип макетлары, ММЧ өчен реклама модульләре, мобиль стенд, веб-битләр, видеозаставкалар, афишалар, чакыру билеты, дипломнар) эшли;
- фестивальнең сайлап алу турында кандидатларның гаризаларын кабул итә, гала-концертта катнашучылар составын билгели;
- приз фондын формалаштыра һәм фестивальдә катнашучылар өчен призлар әзерли;
- фестивальнең барлык этапларында кирәкле мәгълүмати контент, оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итә;
- фестивальгә реклама ярдәме күрсәтә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында реклама яктыртуны тәэмин итә;

- әлеге нигезләмә кысаларында фестивальдә катнашучыларның хокукларын үтәүне тәэмин итә.
4.4. Ресурс базасын әзерләү, фестивальнең барлык этапларын үткәрү өчен куркынычсыз шартлар тудыру смета нигезендә «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан тәэмин ителә.
4.5. Фестиваль гала-концертының сценариен төзү, гомуми куелышын һәм режиссурасын «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ режиссеры башкара.

## 5. Жюри

5.1. Жюри (3 кушымта) оештыру комитеты тарафыннан формалаштырыла һәм «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры боерыгы белән раслана.
5.2. Жюри составына фестивальдә үз тәрбияләнүчеләрен тәкъдим итмәүче юнәлешләр (жанрлар) буенча белгечләр керә.
5.3. Жюри рәисе оештыру комитеты тарафыннан раслана.
5.4. Тавышлар саны бертигез булган очракта (очколар, баллар) жюри рәисе ике тавышка ия.
5.5. Фестиваль вакытында рәсми күзлектән жюри рәисе һәм җаваплы секретарь чыгыш ясарга хокуклы.
5.6. Жюри составы фестиваль барышында, әмма фестивальдә катнашуга гаризалар кабул итүнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча үзгәрергә мөмкин.

## 6. Фестивальдә катнашу шартлары

6.1. Фестивальдә Тукай муниципаль районы территориясендәге авыл җирлегеннән иҗат коллективы катнаша ала.
6.2. Фестивальдә катнашу бушлай.
6.3. Фестивальдә катнашучыларның яше чикләнмәгән.
6.4. Фестивальдә катнашу өчен Kultura.Tuk@tatar.ru электрон адресына яки түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, 113 каб., тел.8(8552)70-13-42 гариза җибәрергә кирәк.
Координатор: «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ балетмейстер - куючысы Кашапова Венера Мансур кызы.
6.5. Әгәр анкетадагы мәгълүматлар чынбарлыкка туры килмәсә, оештыру комитетының иҗат коллективын фестивальдә катнаштырмау хокукы бар.
6.7. Сайлап алу турында катнашучыларны карау нәтиҗәләре буенча иң яхшы иҗат коллективлары гала-концертта катнашуга чакырыла.
6.8. Катнашучыларның алга таба фестиваль финалына үтүе турында карарны бары тик фестивальнең оештыру комитеты һәм жюри әгъзалары гына кабул итә.

## 7. Фестивальнең тематикасы.

7.1. Фестивальнең төп шарты булып тематик, фольклор вокаль-хореографик композиция яки милли йола тәкъдим итү тора. Аутентик фольклор. Фестиваль программасын халык өчен чара рәвешендә үткәрергә кирәк.
7.2. «Гаилә елына» багышланган фестиваль номерлары хуплана.

7.3. Вокаль-хореографик композицияләрнең гомуми озынлыгы 5 минуттан артмый.
7.4. Темасы һәм эчтәлеге кеше абруен кимсеткән, милләтара ызгышка китергән, наркотиклар, тәмәке, алкоголь куллануны пропагандалаган яки башка ысул белән РФ законнарын яисә фестивальдә катнашучыларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозган номерлар фестивальдә катнашырга рөхсәт ителми.

## 8. Фестиваль номерларын бәяләү критерийлары

8.1. Фестиваль эшләренә жюри әгъзалары бәя бирә.
8.2. Эшләр түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.
- номерның бөтенлеге (тематик юнәлеш, реквизитлар куллану, музыкаль бизәлеш, костюм, грим);
- эчтәлекнең булуы, аның сайланган темага туры килүе;
- конкурс номерының сәнгати һәм эстетик дәрәҗәсе;
- композициянең катнашучының яшенә туры килүе;
- композициянең техник катлаулылыгы;
- чыгышның сыйфаты;
- текст, вокаль һәм хореографик материалның бердәмлеге һәм тәэсирлелеге;
- оригинальлек;
- мәгълүматка бай булу;
- бизәлешнең эстетиклыгы;
- фестиваль темасын ачу;
- йоланы, вокаль-хореографик композицияне башкару формасы һәм эчтәлеге;
- реквизитлар, декорация һәм сәхнә костюмнары;
- сәнгатьлелек, эмоциональлек, артистлык.

8.4. Максималь билге – 10 балл.
8.5. Жюриның һәр әгъзасы билгеләр ведомостен төзи һәр катнашучы өчен җыелган баллар суммасын исәпләп чыгара. Нәтиҗә билгесе җыелма ведомостька кертелә.
8.6. Смотр-конкурста җиңүчеләр һәм призерлар иң яхшы күрсәткечләр (баллар) буенча билгеләнә.
8.7. Смотр-конкурска йомгак ясау жюри утырышында үткәрелә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәгә барлык жюри әгъзалары имзалаган бәяләрнең җыелма ведомостьлары теркәлә. Нәтиҗәләргә йомгак һәм анализ жюри рәисенең йомгаклау чыгышында игълан ителә.

## 9. Җиңүчеләрне бүләкләү

9.1. Фестивальдә катнашучыларны бүләкләү гала-концертта үткәрелә.
9.2. Гала-концертта катнашучыларның барысы да катнашучы дипломнары белән бүләкләнә.
9.3. Фестивальдә җиңүчеләр дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнәләр.
9.4. Авыл җирлекләре арасында I, II, III урыннар билгеләнә, дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән тапшырыла.

## 10. Оештыру таләпләре

10.1. Фестивальдә катнашу өчен 14.08.2024 елга кадәр гариза җибәрергә кирәк

10.2. Соңрак бирелгән гаризалар каралмый.

10.3. Катнашучыларны җибәрүче оешмалар яки физик затлар аларның смотр-конкурс уздырыла торган урынга барып кайтуларын тәэмин итәләр.

10.4. Иҗат коллективлары һәм фестиваль кунакларының катнашучыларга иминлек гарантияли ала торган тиешле санда озатып йөрүче затлары булырга тиеш.

10.5 Флеш-туплагычта фестиваль өчен фонограммалар гына булырга тиеш!

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның
«06» 08 3510 номерлы
карарына 2 кушымта

**«Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестивален оештыру комитеты**

**Васильев Юрий Павлович** – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, оештыру комитеты рәисе;

**Низамиева Эльмира Роберт кызы** – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы, оештыру комитеты әгъзасы;

**Габдуллин Айрат Салават улы** – «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры, оештыру комитеты әгъзасы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның
«06» 08 3510 номерлы
карарына 3 кушымта

**«Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестивалендә жюри**

**Васильев Юрий Павлович** – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, жюри рәисе;

**Сафина Ландыш Рафаэль кызы** – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенең тәрбия эше буенча урынбасары, жюри әгъзасы;

**Габдуллин Айрат Салават улы** – «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры, жюри әгъзасы;

**Галишина Юлия Фәүзия кызы** – «Тукай муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ директоры, жюри әгъзасы;

**Кашапова Венера Мансур кызы** – «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ балетмейстер-куючысы, жюри әгъзасы;

**Муллагалиева Лилия Зөфәр кызы** – «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУнең вокал буенча педагогы, жюри әгъзасы.

**«Россия Федерациясендә Гаилә елына» багышланган «Истоки» район фольклор коллективлары фестиваленең муниципаль этабын уздыру графигы**

| Үткәрү датасы һәм вакыты | Үткәрү урыны | Катнашучылар |
|---|---|---|
| **20.08.2024 18:00** | **Мәләкәс авыл мәдәният йорты** | Круглое Поле авыл җирлеге |
| | | Бәтке авыл җирлеге |
| | | Биклән авыл җирлеге |
| | | Иштирәк авыл җирлеге |
| | | Мәләкәс авыл җирлеге |
| **21.08.2024 18:00** | **Күзкәй авыл мәдәният йорты** | Кече Шелнә авыл җирлеге |
| | | Калмия авыл җирлеге |
| | | Боерган авыл җирлеге |
| | | Күзкәй авыл җирлеге |
| **22.08.2024 18:00** | **Иске Абдул авыл мәдәният йорты** | Иске Дөреш авыл җирлеге |
| | | Яңа Бүләк авыл җирлеге |
| | | Теләнче Тамак авыл җирлеге |
| | | Иске Абдул авыл җирлеге |
| | | Сәмәкәй авыл мәдәният йорты |
| **23.08.2024 18:00** | **Князево авыл мәдәният йорты** | Шилнәбаш авыл җирлеге |
| | | Князево авыл җирлеге |
| | | Әҗмәкәй авыл җирлеге |
| | | Калмаш авыл җирлеге |
| **24.08.2024 18:00** | **Борды авыл мәдәният йорты** | Түбән Суыксу авыл җирлеге |
| | | Борды авыл җирлеге |
| | | Мусабай Завод авыл җирлеге |
| | | Комсомолец авыл җирлеге |
| | | Яңа Троицкий авыл җирлеге |